Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты
карары

6 май 2020 ел № 591

Таләп ителмәгән җир өлешләре
милекчеләре булган затлар
исемлеген раслау турында

«Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең әйләнеше турында» 2002 елның 24 июлендәге 101-ФЗ номерлы Федераль законның 12.1 статьясындагы 1,2,6,7,8 пунктчалары нигезендә, Әлмәт муниципаль районы Түбән Абдулла авыл җирлегенең мәгълүмат такталарында һәм Әлмәт муниципаль районы муниципаль берәмлеге сайтында урнаштырылган 2019 елның 5 сентябрендәге 37(1132) номерлы «Альметьевский вестник» газетасында соратылмаган җир өлешләре исемлеген карап, Өлешле милектә катнашучыларның гомуми җыелышының 2020 елның 25 февралендәге 1 номерлы беркетмәсе нигезендә,

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Түбән Абдул авыл җирлеге территориясендә урнашкан авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясенә кертелгән исемлек нигезендә кадастр номеры 16:07:000000:1818, мәйданы 1 883 321 кв.м. булган таләп ителмәгән җир өлешләре милекчеләре булган затлар исемлеген расларга (1 нче кушымта).

2. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары А.Н. Подоваловка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе М.Н. Гирфанов

Әлмәт муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
«6» май 2020 ел № 591
1 нче кушымта

Таләп ителмәгән җир өлешләре милекчеләре
булган затлар исемлеге

| №п/п | Җир өлеше милекчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме | Туган елы |
|---|---|---|
| 1 | Әгъмалов Мөктәсим Әгъмал улы | 26 октябрь 1934 ел |
| 2 | Галиәскәрова Мәрьям Хәсәнша кызы | 4 июль 1926 ел |
| 3 | Галимов Альфрит Максумович | 20 ноябрь 1938 ел |
| 4 | Гыйрфанова Зөләйха Талип кызы | 20 январь 1941 ел |
| 5 | Гыйрфанова Фатыйма Җиһангир кызы | 12 февраль 1927 ел |
| 6 | Нуриева Газҗә Талип кызы | 15 февраль 1926 ел |
| 7 | Хәбибуллин Хәмәтшаһит Әгъмал улы | 30 декабрь 1926 ел |
| 8 | Шәйхетдинова Нурҗиһан Шакир кызы | 10 май 1938 ел |
| 9 | Шәңгәрәева Зәйнәб Кыям кызы | 9 гыйнвар 1929 ел |

Район
Башкарма комитеты җитәкчесенең
икътисад буенча урынбасары А.Н. Подовалов